Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге
Кычытканлы авылы торак пункты
гражданнар җыены КАРАРЫ

«10» апрель 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлеге Кычытканлы авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Алдан расланган карарларда гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәләгә үзгәрешләр кертергә:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 10.11.2023 ел, № 1 карар;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 10.11.2023 ел, № 2 карары,

аны түбәндәге редакциядә расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан тыш, 2024 елда 3400 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (Татарстан Республикасы муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылындагы сусүткәргеч торбаларның аерым участокларын алыштыру һәм суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылы торак пунктында янгын сүндерү тукталышларын сатып алу һәм урнаштыру);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылы торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм тоту, шул исәптән сезонлы тоту);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлегенең Кычытканлы авылында урам яктыртуын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү)ремонтлау;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кычытканлы авыл җирлеге Кычытканлы авылы торак пункты территориясен төзекләндерү);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (МТЗ-82 тракторы өчен тагылмалы җиһазлар сатып алу)».

Халык җыенында рәислек итүче Ф.Р. Сабиров

Кычытканлы авыл җирлеге башлыгы Ф.Р. Сабиров